| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2019. Алексеевск ш.т.б. № 32

**Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 нче елның 5 нче апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 39 нчы матдәсе нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып», тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү өчен, бердәнбер тәэминатчыдан (подрядчы, башкаручыдан) сатып алуны тормышка ашырудан тыш

**карар бирәм:**

1. Бәйгеләр, аукционнар уздыру котировкалар ихтыяҗын һәм киләсе составта тәкъдимнәр соратып алу юлы белән сатып алулар үткәрү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы Бердәм комиссия төзергә:

Бердәм комиссия рәисе:

Алексеева Ирина Владимир кызы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Аукционнар һәм бәйгеләр» МКУ җитәкчесе

Комиссия рәисе урынбасары, комиссия рәисе урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын башкаручы:

Васильев Алексей Дмитрий улы – Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары

Бердәм комиссия әгъзалары:

Крохина Надежда Александр кызы – «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе;

Мифтахова Елена Михаил кызы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары;

Самсонова Людмила Евгений кызы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлегенең баш белгече;

Сафонова Наталья Владимир кызы – «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләре бухгалтериясе» МКУ җитәкчесе;

Свистунов Игорь Константин улы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча);

Харитонов Александр Сергей улы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килештерү буенча)

Бердәм комиссия сәркатибе (тавыш бирү хокукы булмаган):

Данилова Екатерина Александр кызы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Аукционнар һәм бәйгеләр» МКУ баш белгече,

Бердәм комиссия сәркатибе вакытлыча урынында булмау чорында:

Боровкова Светлана Владимир кызы – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Аукционнар һәм бәйгеләр» МКУ баш белгече.

2. Конкурслар, аукционнар уздыру котировкалар ихтыяҗын һәм киләсе составта тәкъдимнәр соратып алу юлы белән сатып алуларны үткәрү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы Бердәм комиссия турында Нигезләмәне расларга (Кушымта).

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма Комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 нче елның 17 нче февралендәге 112 нче номерлы «Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында»;

- «Башкарма комитет җитәкчесенең «Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында» 2014 елның 17 февралендәге 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 4 июлендәге 346 номерлы карары;

- «Башкарма комитет җитәкчесенең «Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия төзү турында» 2014 елның 17 февралендәге 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 30 июнендәге 331 номерлы карары;

- «Башкарма комитетның «Комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 17 февралендәге 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 381 номерлы карары.

4. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru / һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А. Д. Васильевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
28.01.2019 № 32 карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль заказчылары өчен бәйгеләр, аукционнар уздыру, котировкалар ихтыяҗын һәм тәкъдимнәр соратып алу юлы белән сатып алу функцияләрен гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Бәйгеләр, аукционнар уздыру, котировкалар ихтыяҗын һәм тәкъдимнәр соратып алу юлы белән сатып алу функцияләрен гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмә (алга таба – Бердәм комиссия) Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы, Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 нче елның 5 нче апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә төзелгән,

1.2. Әлеге Нигезләмә Бердәм комиссия эшчәнлегенең максатларын, бурычларын, функцияләрен, вәкаләтләрен һәм тәртибен билгели.

## 2. Төп төшенчәләр

2.1. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) Муниципаль заказ бирүче һәм заказ бирүче (алга таба – заказ бирүчеләр) – Муниципаль орган яисә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге исеменнән эш итүче, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән Бюджет йөкләмәләрен кабул итәргә вәкаләтле һәм сатып алуларны гамәлгә ашыручы муниципаль казна учреждениесе, шулай ук сатып алуларны гамәлгә ашыра торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан бирелгән субсидияләр һәм 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә башка чаралар исәбенә гамәлгә ашыручы Алексеевск муниципаль районының бюджет учреждениеләре;

2) Тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү – заказчы тарафыннан 44-ФЗ нмерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырылучы, товар сатып алуны, эшне башкаруны, хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыру яки тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрү турында хәбәр урнаштырудан башлап контракт төзү белән тәгалләнүче гамәлләр җыелмасы;

3) Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы (алга таба – бердәм

мәгълүмат системасы) – 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 матдәсендәге 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат базаларында, мәгълүмат технологияләре һәм мондый мәгълүматны формалаштыруны, эшкәртүне, саклауны тәэмин итә торган техник чаралар турындагы мәгълүмат җыелмасы, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайты (алга таба - рәсми сайт) аша бирү;

4) Электрон мәйданчык – электрон формада тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең ябык ысулларыннан тыш, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 мтдәсендәге 2 нче өлешенең 1нче һәм 2нче пунктлары нигезендә тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең конкурентлы ысуллары үткәрелә торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайт;

5) Электрон мәйданчык операторы – электрон мәйданчыкка ия булган, билгеләнгән капиталының чит ил гражданнарында, гражданлыгы булмаган затларда, чит илләнең юридик затларында өлешләре (акцияләре) егерме биш проценттан артмаган, шул исәптән аның эшләве өчен кирәкле программа-аппарат чаралары белән аның эшләвен тәэмин иткән, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган 44-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 матдәендәге 2 нче өлешенең 1нче һәм 2 нче пунктлары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килә һәм электрон мәйданчык операторлары исемлегенә кертелгән ачык булмаган хуҗалык җәмгыяте;

6) Ачык бәйге – ачык сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр куела;

7) Электрон формадагы ачык бәйге – ачык сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән электрон формада хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр куела;

8) Катнашучылары чикле булган бәйге – сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр һәм өстәмә таләпләр куела, әлеге бәйге җиңүчесе квалификация алды сайлап алуны узган сатып алуларда катнашучылар арасыннан билгеләнә;

9) Электрон формадагы катнашучылары чикле булган бәйге – сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән электрон формада хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр һәм өстәмә таләпләр куела, әлеге бәйге җиңүчесе квалификация алды сайлап алуны узган сатып алуларда катнашучылар арасыннан билгеләнә;

10) Ике этаплы бәйге – сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар

кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр яки бердәм һәм өстәмә таләпләр куела һәм әлеге бәйгенең җиңүчесе дип ике этаплы конкурсның ике этабында да катнашкан катнашучы (шул исәптән, мондый бәйгедә катнашучыларга өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, беренче этапта квалификация алды сайлап алуы узганнар) һәм әлеге конкурсның икенче этабы нәтиҗәләре буенча контрактны үтәүнең иң яхшы шартларын тәкъдим иткән катнашучы таныла;

11) Электрон формадагы ике этаплы бәйге – сатып алу бәйгесе үткәрү һәм документлар кабул итү турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр яки бердәм һәм өстәмә таләпләр куела һәм әлеге бәйгенең җиңүчесе дип бәйгенең ике этабында да катнашкан катнашучы (шул исәптән тиешле өстәмә таләпләргә туры килгән) һәм әлеге бәйгенең икенче этабы нәтиҗәләре буенча контрактны үтәүнең иң яхшы шартларын тәкъдим иткән катнашучы таныла;

12) Сатып алу турындагы мәгълүмат заказчы тарафыннан чикләнмәгән затлар даирәсенә мондый аукцион үткәрү турында хәбәрнамәнең бердәм мәгълүмати системасында һәм аның турында документлар урнаштыру юлы белән хәбәр ителә торган аукцион, сатып алуларда катнашучыларга бердәм таләпләр һәм өстәмә таләпләр куела, мондый аукционны үткәрү оператор тарафыннан электрон мәйданчыкта алып барыла;

13) Катировкалар соратып алу – тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү ысулы, мондый сатып алу турындагы мәгълүмат чикләнмәгән затлар даирәсенә әлеге котировкалар соратып алу турында хәбәрнамәне бердәм мәгълүмати системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә һәм котировока соратып алуда җиңүче дип контрактның иң түбән бәясен тәкъдим иткән сатып алу катнашучысы таныла;

14) Электрон формадагы катировкалар соратып алу – тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү ысулы, мондый сатып алу турындагы мәгълүмат чикләнмәгән затлар даирәсенә электрон формадагы котировкалар соратып алу турында хәбәрнамәне бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә һәм котировока соратып алуда җиңүче дип контрактның иң түбән бәясен тәкъдим иткән сатып алу катнашучысы таныла, әлеге катнашучы электрон формадагы котировкалар соратып алу турындагы хәбәрнамәдә урнаштырылган таләпләргә туры килергә тиеш;

15) Тәкъдимнәр соратып алу – тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү ысулы, мондый сатып алу турындагы мәгълүмат чикләнмәгән затлар даирәсенә әлеге тәкъдимнәрне соратып алу турында хәбәрнамәне һәм аның турында документларны бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә һәм тәкъдимнәр соратып алуда җиңүче дип заказчы тарафыннан товар, эш яки хезмәт күрсәтү таләпләренә иң яхшысы туры килә торган тәкъдим юллаган сатып алу катнашучысы таныла;

16) Тәкъдимнәрне электрон формада соратып алу – тәэмин итүчене

(подрядчы, башкаручыны) билгеләү ысулы, мондый сатып алу турындагы мәгълүмат чикләнмәгән затлар даирәсенә электрон формада тәкъдимнәрне соратып алу турында хәбәрнамәне һәм аның турында документларны бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр ителә һәм тәкъдимнәр соратып алуда җиңүче дип заказчы тарафыннан товар, эш яки хезмәт күрсәтү таләпләренә иң яхшысы туры килә торган тәкъдим юллаган сатып алу катнашучысы танылa.

## 3. Хокукый җайга салу

3.1. Комиссия үз эшчәнлеге барышында Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы белән эш итә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 нче елның 5нче апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 4. Бердәм комиссияне төзү максатлары һәм эш принциплары

4.1.Бердәм комиссия бәйгеләр (ачык бәйге, катнашучылары чикле булган бәйге, ике этаплы бәйге, ябык бәйге, катнашучылары чикле булган бәйге, ике этаплы ябык бәйге), аукционнар (электрон формада аукцион, ябык аукцион) үткәрү, котировкалар һәм тәкъдимнәр соратып алу максатында оештырыла. 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, электрон формада ачык бәйге, катнашучылары чикле булган бәйге, ике этаплы бәйге, электрон аукцион, катировкалар һәм тәкъдимнәр соратып алу үткәрелә, шулай ук Россия Федерациясе хөкүмәтенең 44-ФЗ номерлы Федераль законның 84.1 нче матдәсендәге 3 нче өлештә каралган карары белән билгеләнгән очракларда ябык бәйге, катнашучылары чикле булган ябык бәйге, ике этаплы ябык бәйге, ябык аукцион үткәрелә.

4.2.Бердәм комиссия эшчәнлегенең принциплары:

1) Бюджеттан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан бүлеп бирелгән финанс чараларын нәтиҗәлелеге һәм экономияле куллану;

2) Тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү процедурасының гавами, хәбәрдар, ачык һәм үтә күренмәле булуы;

3) намуслы конкуренцияне тәэмин итү, дискриминацияне булдырмау, сатып алуларның аерым катнашучылары өчен чикләүләр яисә өстенлекләр кертүгә юл куймау, мондый өстенлекләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш;

4) тәэмин итүчеләрне (подрядчылар, башкаручыларны) билгеләгәндә хезмәт урыныннан файдалану мөмкинлекләрен һәм коррупцияне юкка чыгару;

5) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән

очракларда, тәэминатчыны (подрядчы, башкаручыны) билгеләү процедураларын үткәрү барышында билгеле булган мәгълүматларны фаш итүгә юл куймау.

## 5. Бердәм комиссиянең функцияләре

### 5.1. Ачык бәйге

5.1.1. Бердәм комиссия ачык бәйгедә катнашуга гаризалар салынган конвертларны бәйге документларында күрсәтелгән гаризалар бирү вакыты җиткәннән соң ачуны гамәлгә ашыра. Ачык бәйгедә катнашу өчен гаризалар салынган конвертлар ачык рәвештә бәйге документларында күрсәтелгәнчә билгеле бер вакытта, урында, билгеләнгән тәртиптә ачыла. Ачык бәйгедә катнашуга килгән гаризалар салынган барлык конвертлар бер көндә ачыла.

5.1.2. Ачык бәйгедә катнашу өчен гаризалар салынган конвертларны ачар алдыннан яки берничә лот буенча ачык бәйге уздырылган очракта, бердәм комиссия мондый конвертларны ачканда, катнашучы һәр лотка карата мондый конвертларны ачу алдыннан, конкурста катнашучыларга ачык бәйгедә катнашу өчен гаризалар бирү мөмкинлеге булуын, ачык бәйгедә катнашу өчен гаризалар бирү, мондый конвертларны ачканчы бирелгән гаризаларны үзгәртү яки кире алу мөмкинлеге булуы турында игълан итә. Шул ук вакытта Бердәм комиссия ачык бәйгедә катнашу өчен ике һәм аннан да күбрәк гариза бирү нәтиҗәләрен игълан итә.

5.1.3. Бердәм комиссия ачык бәйгедә катнашуга килгән гаризалар салынган конвертларны ача, әгәр мондый конвертлар һәм гаризалар заказ бирүчегә конвертларны ачканчы килгән булса. Ачык бәйгедә катнашучының бер үк лотка карата ачык бәйгедә катнашу өчен ике һәм аннан да күбрәк гариза бирү очрагы ачыкланган очракта, элек бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризалары кире алынмаган булса, әлеге катнашучының бер үк лотка карата бирелгән барлык гаризалары да каралмый һәм үзенә кире кайтарыла.

5.1.4. Әгәр бәйге документлары нигезендә заказчының бәйгедә катнашучы берничә кеше белән ике һәм аннан күбрәк эзләнү һәм фәнни-тикшеренү эшләрен башкаруга контракт төзү хокукы каралган булса, бәйгедә катнашу өчен бер үк вакытта ике һәм аннан да күбрәк эшкә карата бирелгән гариза каралмый һәм конкурста катнашучыга кире кайтарыла.

5.1.5. Бердәм комиссия ачык бәйгедә катнашу өчен гаризалар салынган конвертларны ачу турында беркетмә алып бара. Күрсәтелгән беркетмә Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан мондый конвертларны ачканнан соң һәм әлеге беркетмәгә кул кую датасыннан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча имзалана һәм бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла. Фәнни-тикшеренү эшләрен башкару өчен контракт төзү максатыннан ачык бәйге уздырганда, сатып алуның берничә катнашучысы белән контракт төзү, шулай ук ике һәм аннан күбрәк эзләнү, фәнни-тикшеренү эшләрен башкару рөхсәт ителгән очракта, беркетмә кул куелган көннән алып өч эш көне эчендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

5.1.6. Бердәм комиссия вазифасына бәйге гаризаларын карау һәм бәяләү керә.

5.1.7. Бәйгедә катнашу өчен гариза биргән катнашучы бәйге документларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәсә, яки мондый гариза бәйге документларында күрсәтелгән таләпләргә туры килми дип табылса, шул исәптән бәйгедә катнашучы әлеге гаризада билгеләнгән эшләрне тәэмин итә алмый дип танылса, шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган очракларда да Бердәм комиссия аларның гаризасын кире кага ала. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 51 нче матдәсендәге 2 нче өлешенең 1 нче пунктының «ж» һәм «з» пунктларында каралган документлар булмауга бәйле рәвештә, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товар, эш, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очракыннан тыш, бәйгедә катнашуга бирелгән гариза кире кагылырга тиеш түгел.

5.1.8. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 51 нче матдәсендәге 2 нче өлеше нигезендә бәйгедә катнашырга бирелгән документларда мәгълүматның дөрес булмавы ачыкланган очракта, бердәм комиссия мондый катнашучыны бәйгедә катнашудан, аны үткәрүнең теләсә кайсы этабында, төшереп калдырырга тиеш.

5.1.9. Бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре Бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау һәм бәяләү беркетмәсендә теркәлә.

5.1.10. Бердәм комиссия бәйге документларында күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәйге җиңүчесен ачыклау өчен кире кагылмаган, бәйгедә катнашуга бирелгән гаризаларны бәяләүне гамәлгә ашыра. Бәйгедә катнашуга бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе барлык шундый гаризаларны кире какса яки бер генә шундый гариза бәйге документларында күрсәтелгән таләпләргә туры килә икән, конкурс үтмәгән дип таныла.

5.1.11. Бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә Бердәм комиссия бәйгедә катнашу өчен һәр бирелгән гаризага, контрактны үтәү шартлары булган файда дәрәҗәсен кимету тәртибендә, тәртип номеры бирә. Контрактны үтәүнең иң яхшы шартларын тәкъдим иткән бәйгедә катнашучының гаризасына беренче номер бирелә. Бәйгедә катнашу өчен бирелгән берничә гаризада контрактны үтәү шартлары бер үк төрле булса, кечерәк тәртип номеры бер үк шартларда башкаларына караганда алданрак килгән гаризага бирелә. Бәйгенең җиңүчесе дип бәйге документларында күрсәтелгән критерийлар нигезендә контрактны башкаруның иң яхшы шартларын тәкъдим иткән һәм бәйгедә катнашу өчен биргән гаризасына беренче номер бирелгән бәйгедә катнашучы таныла.

5.1.12. Бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау һәм бәяләү нәтиҗәләре түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш булган гаризаларны карау һәм бәяләү беркетмәсендә теркәлеп бара:

- мондый гаризаларны карау һәм бәяләү урыны, көне һәм үткәрү вакыты;
- бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризалары каралган катнашучылар турында мәгълүмат;

- бәйгедә катнашу өчен биргән гаризалары кире кагылган катнашучылар турында мәгълүмат, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре һәм бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларда булган һәм бәйге документларының таләпләренә туры килми торган бәйге документлары нигезләмәләре;

- комиссиянең һәр әгъзасының бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны кире кагу турындагы карары;

- бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү тәртибе;

- бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның бәяләү критерийлары буеча һәркайсына туры килүенә әһәмият бирү; конкурста катнашу өчен заявкалар конкурста катнашуга гаризаларны бәяләү критерийларының һәркайсы буенча бирелгән;

- бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән әлеге гаризаларга тәртип номерларын бирү турында карар;

- бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларына беренче һәм икенче номерлар бирелгән катнашучыларның исеме (юридик затлар өчен), фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар өчен), бәйгедә катнашучыларның почта адреслары.

5.1.13. Бәйге документлары таләпләренә туры килү-килмәү буенча бәйгедә катнашу өчен бирелгән бердәнбер гаризаны карау нәтиҗәләре бәйгедә катнашу өчен бердәм гаризаны карау беркетмәсендә теркәлә, анда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- мондый гаризаларны карау урыны, көне, вакыты;

- бәйгедә катнашу өчен бердәнбер гариза биргән бәйгедә катнашучының исеме (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм почта адресы;

- комиссиянең һәр әгъзасының мондый гаризаның 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә һәм бәйге документларына туры килүе турындагы карары;

- бәйгедә катнашу өчен бердәнбер гариза биргән бәйгедә катнашучы белән контракт төзү мөмкинлеге турында карар.

5.1.14. Әлеге Нигезләмәнең 5.12 һәм 5.1.1.13 пунктларында күрсәтелгән беркетмәләр ике нөсхәдә төзелә һәм Бердәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Әлеге беркетмәләрнең һәркайсының бер нөсхәсе вәкаләтле органда саклана, икенче нөсхә кул куелган көннән соң өч эш көне эчендә, бәйгедә катнашу өчен бердәнбер гариза биргән, контракт проектында теркәлгән, бәйге җиңүчесенә яки бәйгедә катнашучыга җибәрелә, әлеге бәйгедә җиңүче, яки бәйгенең бердәнбер катнашучысы тәкъдим иткән контракт шартлары кертелгән контракт проекты кушымта буларак бирелә. Бәйгедә катнашу өчен гаризаларны карау һәм бәяләү беркетмәсе, бәйгедә катнашу өчен бердәнбер гаризаны карау беркетмәсе вәкаләтле орган тарафыннан бердәм мәгълүмат системасында күрсәтелгән беркетмәләргә кул кую датасыннан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5.1.15. Бердәм комиссия ачык бәйгене үткәрү юлы белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедурасын тормышка ашырганда

шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә башка гамәлләр дә башкара.

## 5.2.Электрон формадагы ачык бәйге

5.2.1. Бердәм комиссия тарафыннан электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү срогы биш эш көненнән дә артмаска тиеш, ә контрактның башлангыч (максималь) бәясе бер миллион сумнан артмаса, күрсәтелгән гаризаларны бирү вакыты тәмамланганнан соң бер эш көне. Электрон формада товар белән тәэмин итү, эш башкару яки фән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча ачык бәйге уздырылган очракта, бу срок контрактның башлангыч (максималь) бәяләренә бәйсез рәвештә күрсәтелгән гаризаларны бирү вакыты тәмамланганнан соң ун эш көненнән дә артмаска тиеш.

5.2.2. Бердәм комиссия электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче матдәсендәге 4 нче өлештә каралган мәгълүматны үз эченә алган гаризаларның беренче өлешләрне карау һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча сатып алу катнашучысына, әлеге бәйгедә катнашу теләген белдереп гариза биргән катнашучыга, бәйгедә катнашырга рөхсәт бирә ала һәм аны бәйгенең катнашучысы дип таный яки 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.5 нче матдәсенең 3 нче өлешендә каралган тәртиптә һәм андагы нигезләр буенча катнашучыны бәйгедә катнаштырырга рөхсәт бирмәве, бәйген читләштерүе турында хәбәр итә.

5.2.3. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучыга түбәндәге очракта электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу рөхсәт ителми:

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче матдәсенең 4 нче өлешендә каралган мәгълүматны тапшырмау (контракт системасы турында законда каралган очраклардан тыш) яисә дөрес булмаган мәгълүмат бирү;
- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучыларның тәкъдимнәре 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче матдәсендәге 4 нче матдәнең 3 нче пунктында каралган таләпләргә һәм электрон формада ачык бәйге үткәрү турындагы хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә, бәйге документларына туры килмәү;
- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучы гаризасының беренче өлешендә мондый катнашучы турында һәм (яки) аларга тәкъдим ителә торган контракт бәясе турында белешмәләрне күрсәтү.

5.2.4. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашырга рөхсәт бирмәү 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.5 нче матдәсендәге 3 нче өлештә каралмаган нигезләр буенча рөхсәт ителми.

5.2.5. Бердәм комиссия мондый бәйгедә катнашуга кертелгән сатып алуларда катнашучыларның электрон формадагы ачык бәйгедә катнашуга бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен бәяләүне, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 32 нче матдәсендәге 1 нче өлешенең 3 нче пунктында билгеләнгән критерий буенча (бәйге документларында бу критерий билгеләгән булса),

гамәлгә ашыра. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.5 нче матдәсендәге 8 нче өлеше нигезендә үткәрелмәгән дип танылган очракта тормышка ашырылмый.

5.2.6. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирлгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча бердәм комиссия мондый бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү беркетмәсен тутыра, ул Бердәм комиссия утырышында катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан мондый бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау срогы тәмамлану көненнән дә соңга калмыйча имзалана. Күрсәтелгән беркетмә үз эченә алырга тиеш мәгълүмат:

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү урыны, датасы, вакыты турында;
- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның идентификация номеры турында мәгълүмат;
- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен гариза биргән һәм аның бу бәйгедә катнашуын тану яисә бу карарны нигезләп, шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен, бәйге документларын күрсәтеп, әлеге катнашучының электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу гаризасының, һәм электрон формадагы ачык бәйгедә катнашуга гариза нигезләмәләре, бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәвен күрсәтеп, әлеге бәйгедә катнаштырудан баш тарту турындагы мәгълүмат;
- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучының һәр әгъзасына карата бердәм комиссия карары турында мондый бәйгедә катнашу өчен рөхсәт алу һәм аның әлеге бәйгедә катнашуын тану яисә мондый бәйгедә катнашутырудан баш тарту турында мәгълүмат;
- № 44-ФЗ Федераль законның 32 нче матдәсендәге 1 нче өлешенең 3 нче пунктында билгеләнгән критерийлар буенча (бәйге документларында критерия билгеләнгәндә), электрон формадагы ачык бәйгедә катнашуга бирелгән гаризаларны бәяләү тәртибе турында мәгълүмат, һәм бердәм комиссия составында булган һәр әгъзасының электрон формадагы ачык бәйгедә катшашырга гариза биргән һәр катнашучыга карата үткәрелгән бәйге документларында каралган критерийлар буенча баллар бирү турында карары.

5.2.7. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү беркетмәсенә 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче матдәсендәге 4 нче өлешенең 2 нче пунктында каралган мәгълүмат бирелә (мондый мәгълүмат булган очракта), һәм электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү срогы тәмамланганнан көннән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән беркетмә заказчы тарафыннан электрон мәйданчык операторына җибәрелә.

5.2.8. Әгәр бердәм комиссия электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен биргән гаризаларың беренче өлешләрне карап тикшерү һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча барлык катнашучыларны да әлеге бәйгедә катнаштырудан

баш тарту турында яки анда катнашу өчен гариза биргән яки мондый бәйгедә катнашу өчен гариза биргән сатып алуларның бер генә катнашучысын тану турында карар кабул итсә, электрон формадагы ачык бәйге үтмәгән дип кабул ителә. Ачык формадагы электрон бәйгенең бәйгедә катнашу өчен биргән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү беркетмәсенә әлеге бәйгенең үтмәве турында мәгълүмат кертелә.

5.2.9. Бердәм комиссия ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен электрон формада карый һәм бәяли. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү срогы өч эш көненнән дә артмаска тиеш, ә контрактның башлангыч (максималь) бәясе бер миллион сумнан артмаса, әлеге срок заказ бирүчегә мондый бәйгедә катнашу өчен гаризаның икенче өлешен җибәргәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча үтәлергә тиеш. Электрон формада товар белән тәэмин итүгә, эш башкаруга яки фән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә хезмәт күрсәтүгә ачык бәйге уздырылган очракта, заказ бирүчегә контрактның башлангыч (максималь) бәясе күләменә бәйсез рәвештә, электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлеше җибәрү датасыннан башлап, бу срок биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

5.2.10. Бердәм комиссия тарафыннан 44-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 нче матдәсендәге 11 нче өлешендә каралганча, бирелгән гаризаларның, документларның һәм мәгълүматның, икенче өлешен карау нәтиҗәләре нигезендә, әлеге бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаның бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында карар кабул ителә.

5.2.11. электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гариза бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килми дип түбәндәге очракларда танылa:

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче матдәсендәге 6 нчы өлешенең 1-3 нче, 7 нче пунктларында каралган документлар һәм мәгълүмат тапшырылмаган очракта яисә әлеге документлар һәм мәгълүмат бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 24.1 нче матдәсендәге 11 нче өлешендә, 54.4 нче матдәсендәге 4 нче һәм 6 нчы өлешләрендә каралган документларда һәм мәгълүматта, мондый бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау датасына һәм вакытына дөрес булмаган мәгълүмат булган очракта;

- мондый бәйгедә катнашучының 44-ФЗ номерлы Федераль законның 31 нче матдәсендәге 1 нче өлеше, 1.1 нче һәм 2.1 нче өлешләре (мондый таләпләр булган очракта) нигезендә бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәү очрагында;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган очракларда;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4нче матдәсендәге 6 нчы өлешенең 5 нче пунктында каралган документлар тапшырылмаган очракта, аларга карата 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсендә каралган

тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашырганда.

5.2.11. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучының биргән мәгълүматлары дөрес булмавы ачыкланса, бердәм комиссия мондый катнашучыны әлеге бәйгедә катнашудан аны үткәрүнең теләсә кайсы этабында төшереп калдырырга тиеш.

5.2.12. Бердәм комиссия, мондый бәйгедә җиңүчене бәйге документларында күрсәтелгән һәм гаризаның икенче өлешенә караган критерийлар нигезендә ачыклау өчен (бәге документларында бу критерийларны билгеләгәндә), аларга карата бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килү турында карар кабул ителгән, электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен бәяли. Әлеге гаризаларны бәяләү электрон формадагы ачык бәйге үткәрелмәгән дип тану очрагында, № 44-ФЗ Федераль законның 54.7 нче матдәендәге 9 нчы өлеше нигезендә гамәлгә ашырылмый.

5.2.13. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү нәтиҗәләре электрон формадагы ачык бәйгенең икенче өлешләрен бәяләү нәтиҗәләрен теркәү беркетмәсендә языла һәм утырышта катнашучы барлык комиссия әгъзалары тарафыннан гаризаларның икенче өлешен карап тикшерү тәмамланганнан соң имзалана. Әлеге беркетмәдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү урыны, датасы, вакыты турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризалары каралган электрон формадагы бәйгенең катнашучылары турында мәгълүмат;

- чыгарылган карарны нигезләп, шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен күрсәтеп, бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләмәвен, әлеге гаризага туры килми торган бәйге документларын һәм бу таләпләргә туры килми торган электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гариза нигезләмәләрен күрсәтеп электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаның туры килүе яки туры килмәве турында мәгълүмат;

- бердәм комиссиядге һәр әгъзасының һәр катнашучының электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен биргән гаризасына карата карары турында мәгълүмат;

- бәйге документлары белән билгеләнгән критерийлар буенча, бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның электрон формадагы ачык бәйгенең һәр катнашучысына карата 44-ФЗ номерлы Федераль законның 32 нче матдәсендәге 1 нче өлешенең 3 нче пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча аңа баллар бирү турында чыгарган карары теркәлгән электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен биргән гаризаларны бәяләү тәртибе турында мәгълүмат;

5.2.14. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү беркетмәсе электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен биргән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү срогы тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча вәкаләтле орган

тарафыннан электрон мәйданчык операторына җибәрелә. Күрсәтелгән беркетмә алганнан соң бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү беркетмәсен һәм электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү беркетмәсен бердәм мәгълүмат системасына һәм электрон мәйданчыкка урнаштыра.

5.2.15. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү Бердәм комиссия тарафыннан барлык килгән гаризаларны кире каккан очракта яки арадан бер гариза гына һәм катнашучы бәйге документларында күрсәтелгән таләпләргә туры килсә, электрон формадагы ачык бәйге үтмәгән дип танылa. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү беркетмәсенә электрон формадагы ачык бәйгенең үтмәве турында мәгълүмат теркәлә.

5.2.16. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.6 нчы матдәсендәге 7 нче өлештә күрсәтелгәнчә, ахыргы тәкъдимнәр тапшыру беркетмәсен электрон мәйданчык операторыннан алган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау һәм бәяләү беркетмәсендә һәм электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау һәм бәяләү беркетмәсендә урын алган электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм комиссия электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән һәр гаризага контрактны үтәү шартлары булган файда дәрәҗәсен киметү тәртибендә тәртип номеры бирә. Контрактны үтәүнең иң яхшы шартлары булган электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризага беренче номер бирелә. Әгәр дә электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның берничәсендә контрактны үтәү шартлары бер үк төрле булса, электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен, үз эченә шундый ук шартларны алган башка гаризалардан алданрак килгән гаризага башка гаризаларга караганда кечрәк тәртип номеры бирелә.

Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре электрон формадагы ачык бәйге нәтиҗәләрен ясау беркетмәсендә теркәлә ул утырышта катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү 44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.7 нче матдәсендәге 9 нчы өлеш нигезендә үткәрелмәгән дип танылган очракта тормышка ашырылмый.

5.2.17. Электрон формадагы ачык бәйге нәтиҗәләрен үткәрү беркетмәсендә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- электрон формада үткәрелгән ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризалары каралган катнашучылар турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен гариза биргән сатып алуларда катнашучыга (44-ФЗ номерлы Федераль законның 54.4 нче

матдәсендәге 10 нчы өлеш нигезендә бирелгән аның идентификация номерын күрсәтеп) бәйгедә катнашырга рөхсәт бирү турында һәм әлеге сатып алуларда катнашучыны бәйгенең катнашучысы дип тану яки әлеге карарны нигезләп, шул исәптән, әлеге катнашучының электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу гаризасына туры килми торган 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен һәм электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен гариза бирү нигезләмәләрен күрсәтеп, бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килми торган нигезләмәләрне күрсәтеп мондый бәйгедә катнаштырудан баш тарту турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучының һәркайсына карата бердәм комиссиянең һәр әгъзасының бәйгедә катнашу өчен рөхсәт алу һәм анда катнашуны тану яки мондый бәйгедә катнаштырудан баш тарту турында чыгарылган карары турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларның бәйге документлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында мәгълүмат, шул исәптән электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу гаризасына туры килми торган Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен һәм әлеге таләпләргә туры килми торган электрон формадагы ачык бәйгедә катнашуга гариза бирү нигезләмәләрен күрсәтеп;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен гариза биргән һәр карнашучының гаризасына карата бердәм комиссиянең һәр әгъзасының чыгарган карары турында мәгълүмат;

- бәйге документлары белән билгеләнгән критерийлар буенча электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү тәртибе һәм бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның электрон формадагы ачык бәйгедә катнашучыга карата, аңа билгеләнгән критерийлар буенча, баллар бирү турында карар кабул итүе турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларга, мондый бәйгедә катнашуны бәяләү критерийларының һәркайсы буенча, бирелгән әһәмият турында мәгълүмат;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән әлеге гаризаларга тәртип номерларын бирү турындагы карар;

- электрон формадагы ачык бәйгедә катнашу өчен биргән гаризаларына беренче һәм икенче номер бирелгән электрон формадагы ачык бәйге катнашучыларның исемнәре (юридик затлар өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), почта адресы турында мәгълүмат.

## 5.3. Катнашучылары чикле булган бәйге

5.3.1. Катнашучылары чикле булган бәйге үткәргәндә Бердәм комиссия тарафыннан № 44-ФЗ Федераль законның 56 нчы матдсендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, ачык бәйгене, әлеге Нигезләмәнең 5.1 нче пунктын үткәрү турында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## 5.4. Электрон формадагы катнашучылары чикле булган бәге

5.4.1. Электрон формадагы катнашучылары чикле булган бәге үткәргәндә Бердәм комиссия тарафыннан 44-ФЗ номерлы Федераль законның 56.1 нче матдәсендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, электрон формадагы ачык бәйге үткәрү турында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## 5.5. Ике этаплы бәйге

5.5.1. Ике этаплы бәйге үткәргәндә бердәм комиссия тарафыннан 44-ФЗ номерлы Федераль законның 57 нче матдәсендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, ачык бәйге үткәрү турында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

5.5.2. Ике этаплы бәйгенең беренче этабында Бердәм комиссия 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә мондый бәйгедә катнашу өчен беренчел гаризаларны биргән катнашучылар белән әлеге гаризаларда булган теләсә нинди сатып алу объекты буенча мондый бәйгедә катнашучыларның тәкъдимнәре турында фикер алышу үткәрә. Ике этаплы бәйгедә катнашучыларның тәкъдимнәре буенча фикер алышканда Бердәм комиссия ике этаплы бәйгедә катнашучыларның барысына да әлеге фикер алышуларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр тудырырга тиеш. Мондый бәйгедә катнашучы һәр кешенең тәкъдимнәре буенча фикер алышу барышында барлык катнашучылар да катнаша ала.

5.5.3. Ике этаплы бәйгенең беренче этабын үткәрү вакыты мондый Бәйгедә катнашуга беренчел гаризалар салынган конвертларны ачу датасыннан егерме көннән дә артмаска тиеш.

5.5.4. Ике этаплы бәйгенең беренче этабында үткәрелгән нәтиҗәләр Бердәм комиссия тарафыннан аның беренче этабы беркетмәсендә теркәлә һәм Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан мондый бәйгенең беренче этабы тәмамланганнан соң имзалана һәм күрсәтелгән беркетмәгә кул кую датасыннан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла. Ике этаплы бәйгенең беренче этабы беркетмәсендә ике этапның беренче этабын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты, исеме (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (физик зат өчен), мондый бәйгедә катнашучының почта адресы, мондый бәйгедә катнашу өчен гариза салынган конверт, сатып алу объекты буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

5.5.5. Ике этаплы бәйгенең беренче этабында үткәрелгән квалификация алды сайлап алу нәтиҗәләре буенча сатып алуның барлык катнашучылары да билгеләнгән бердәм таләпләргә һәм өстәмә таләпләргә туры килми дип танылган булса, яисә сатып алуларда катнашучыларның берсе генә әлеге таләпләргә туры килә дип танылган булса, ике этаплы бәйге үткәрелмәгән дип таныла.

5.5.6. Ике этаплы бәйгенең икенче этабында Бердәм комиссия ике этаплы бәйгенең беренче этабын үткәрүдә катнашкан катнашучыларның барысына да ике этаплы бәйгедә катнашу өчен, мондый бәйгенең беренче этабыннан соң

төгәлләштерелгән сатып алу шартлары исәпкә алынган контракт бәясе күрсәтелгән, соңгы гаризаларны китерергә тәкъдим итә.

5.5.7. Ике этаплы бәйгенең беренче этабын үткәрүдә катнашкан катнашучы ике этаплы бәйгенең икенче этабында катнашудан баш тартырга хокуклы.

5.5.8. Ике этаплы бәйгедә катнашу өчен соңгы гаризалар ике этаплы бәйгенең беренче этабында катнашучылар тарафыннан бирелә һәм ачык бәйге үткәрү турында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә, ачык бәйге үткәрү өчен билгеләнгән һәм ике этаплы бәйгедә катнашу өчен ахыргы гаризалар салынган конвертларны ачу датасыннан исәпләнгән срокта ачык бәйге үткәрү турында  нигезләмә нигезендә Бердәм комиссия тарафыннан карала һәм бәяләнә.

5.5.9. Әгәр ике этаплы бәйгедә катнашу өчен соңгы гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң бер генә гариза бирелгән яки бер генә гариза да бирелмәгән булса, яисә күрсәтелгән бер гариза гына 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм бәйге документларына туры килә дип табылса, яисә бәйге комиссиясе гаризаларның барлык мәгълүматларын кире каккан очракта, ике этаплы бәйге үтмәгән дип танала.

## 5.6. Электрон формадагы ике этаплы бәйге

5.6.1. Электрон формадагы ике этаплы бәйге үткәргәндә Бердәм комиссия тарафыннан контракт системасы турындагы закон нигезләмәләре, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 57.1 нче матдәсендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, электрон формадагы ачык бәйге нигезләмәсе куллана. Электрон формадагы ике этаплы бәйгенең беренче этабын уздыру барышында, электрон формадагы ике этаплы бәйгедә катнашучыларга карата бердәм таләпләр һәм өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 57.1 нче матдәсендә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, өстәмә таләпләргә кагылышлы законның 56.1 нче матдәсе нигезләмәләре кулланыла.

## 5.7. Электрон аукцион

5.7.1. Бердәм комиссия электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешен сатып алына торган товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә карата мондый аукцион турындагы документта билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

5.7.2. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау срогы, күрсәтелгән гаризаларны бирү вакыты тәмамланганнан соң,  җиде көннән артмаска тиеш, ә контрактның башлангыч (максималь) бәясе өч миллион сумнан артмаса, мондый срок күрсәтелгән гаризаларны бирү вакыты тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

5.7.3. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау нәтиҗәләре буенча бердәм комиссия мондый аукционда катнашу өчен гариза биргән сатып алуларда катнашучыга аукционда катнашырга

рөхсәт бирү һәм аны әлеге аукцион катнашучысы итеп тану яки аны әлеге аукционда катнаштырудан баш тарту турында карар кабул итә.

5.7.4. Электрон аукционда катнашучыга түбәндәге очракларда анда катнашырга рөхсәт ителми:

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 66 нчы матдәсендәге 3 нче өлешендә каралган мәгълүматны тапшырмау яки дөрес булмаган мәгълүмат бирү;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 66 нчы матдәсендәге 3 нче өлештә каралган мәгълүматның мондый аукцион турындагы документ таләпләренә туры килмәве.

Башка сәбәпләр буенча электрон аукционда катнаштырудан баш тарту рөхсәт ителми.

5.7.5. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешләрен карау нәтиҗәләре буенча Бердәм комиссия анда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау беркетмәсен рәсмиләштерә һәм әлеге беркетмә Бердәм комиссия утырышында катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан әлеге гаризаларны карау срогы тәмамланган көн датасыннан да соңга калмыйча имзалана. Күрсәтелгән беркетмә электрон аукционда катнашу өчен гаризаларны карау вакыты тәмамланганнан соң да соңга калмыйча вәкаләтле орган тарафыннан электрон мәйданчык операторына җибәрелә һәм бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән беркетмә үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- мондый аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның идентификация номеры турында;

- мондый аукционда катнашу өчен гариза биргән катнашучыга әлеге сатып алуларда катнашырга рөхсәт итү турында, анда катнашу өчен тиешле идентификация номеры бирелгән һәм әлеге аукционда катнашучыны сатып алу катнашучысы дип тану яисә әлеге карарны нигезләп, шул исәптән карала торган гаризага туры килми торган аукцион турындагы документларның нигезләмәләрен, аның турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми торган нигезләмәләрне күрсәтеп, аукционда катнаштырудан баш тарту турында мәгълүмат;

- Бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның катнашучыларның һәркайсына карата мондый аукционда катнашу өчен рөхсәт алу һәм аның аукционда катнашуын тану яки мондый аукционда катнаштырудан баш тарту турындагы карары хакында мәгълүмат;

- Электрон аукционның катнашуысы дип танылган сатып алуларда катнашучыларның тәкъдимнәре арасында, әгәр товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне рөхсәт итү шартлары, тыюлар, чикләүләр № 44-ФЗ Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә электрон аукцион турындагы документларга заказ бирүче тарафыннан билгеләнгән булса, чит илдән яисә чит дәүләтләр төркеменнән товар, эшләр китерү, чит ил гражданнары тарафыннан төрле хезмәтләр күрсәтү турында тәкъдимнәр булу турында мәгълүмат;

5.7.6. Әгәр электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның беренче өлешен карау нәтиҗәләре буенча бердәм комиссия әлеге аукционда катнашуга гариза биргән барлык сатып алу катнашучыларына әлеге аукционда

катнашырга рөхсәт бирмәү яки әлеге аукционда катнашуга гариза биргән бер генә сатып алу катнашучысын, аукцион катнашучысы дип танылу турында Карар кабул итсә, мондый аукцион үтмәгән дип таныла. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау беркетмәсенә мондый аукционны үтмәгән дип тану турында мәгълүмат кертелә.

5.7.7. Бердәм комиссия электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен электрон мәйданчык операторы тарафыннан җибәрелгән мәгълүматны һәм электрон документларны 44-ФЗ номерлы Федераль законның 68 нче матдәсендәге 19 нчы өлеше нигезендә, аларның мондый аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе ягыннан карый.

5.7.8. Бердәм комиссия тарафыннан электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау нәтиҗәләре нигезендә әлеге аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның 44-ФЗ номерлы Федераль законның 69 нчы матдәсендә каралган тәртиптә һәм нигезләр буенча билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында Карар кабул ителә. Күрсәтелгән карарны кабул итү өчен бердәм комиссия электрон мәйданчыкта аккредитация алган мондый аукционда катнашучылар реестрында булган катнашучының әлеге гаризасын тапшыруы турында мәгълүматны карый.

5.7.9. Бердәм комиссия 44-ФЗ номерлы Федераль законның 68 нче матәсендәге 19 нчы өлеше нигезләмәләре нигезендә, мондый аукцион турында документлар белән билгеләнгән биш таләпкә туры килү турында Карар кабул ителгәнче, электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карый. Әгәр мондый аукционда уннан азрак катнашучы катнашса һәм әлеге аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның биштән дә киме куелган таләпләргә туры килә икән, Бердәм комиссия күрсәтелгән аукционда катнашу өчен барлык катнашучылар тарафыннан бирелгән гаризаларның икенче өлешен карый. Әлеге гаризаларны карау катнашучының контрактның иң түбән бәясен тәкъдим иткән мондый аукционда катнашу өчен гариза бирүдән башлана һәм 44-ФЗ номерлы Федераль законның 68 нче матдәсендәге 18 нче өлеше нигезендә әлеге гаризаларны төркемләп тәртипкә салуны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.7.10. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карауның гомуми вакыты электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштыру датасыннан соң өч эш көненнән дә артмаска тиеш.

5.7.11. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гариза мондый аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми дип түбәндәге очракларда таныла:

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 66 нчы матдәсендәге 3 нче һәм 5нче өлешләрендә каралган документларны һәм мәгълүматны тапшырмау, әлеге документларның һәм мәгълүматның мондый аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, күрсәтелгән документларда мондый аукционда катнашучы турында мондый аукционда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты һәм датасына дөрес булмаган мәгълүмат булу;

- мондый аукционда катнашучының 44-ФЗ номерлы Федераль законның 31 нче матдәсендәге 1 нче өлеше, 1.1 һәм 2 нче өлешләре нигезендә билгеләнгән таләпләргә (мондый таләпләр булганда) туры килмәве;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган очракларда.

5.7.12. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаның мондый аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турындагы карарны 44-ФЗ номерлы Федераль законның 69 нчы матдәсендәге 6 нчы өлештә каралмаган нигезләр буенча кабул итү рөхсәт ителми. Электрон аукционда катнашуга бирелгән гариза анда 44-ФЗ номерлы Федераль законның 66 нчы матдәсендәге 5 нче өлешенең 5 нче пунктында каралган электрон документлар һәм мәгълүмат булмау сәбәпле, шулай ук, аларга карата 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очракларыннан тыш, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 66 нчы матдәсендәге 5 нче өлешенең 6 нчы пункты нигезендә, мондый аукцион турында документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми дип таныла алмый.

5.7.13. Электрон аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре нәтиҗәләр ясау беркетмәсендә теркәлә, ул әлеге гаризаларны карауда катнашучы барлык Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм әлеге беркетмәгә кул кую датасыннан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча электрон мәйданчыкта һәм бердәм мәгълүмат системасында вәкаләтле орган тарафыннан урнаштырыла. Күрсәтелгән беркетмәдә мондый аукционда катнашу өчен бирелгән биш гаризаның идентификация номеры турында мәгълүмат булырга тиеш (мондый аукционда катнашу өчен бирелгән биш гаризаның әлеге аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Карар кабул ителгән очракта, яки мондый аукционда катнашкан барлык катнашучылар тарафыннан бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау нигезендә Бердәм комиссия тарафыннан мондый аукционда катнашу өчен бирелгән бер гаризаның билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында, ләкин әлеге гаризаларның билгеләнгән таләпләргә караганда биштән дә ким булуы турында кабул иткән очракта), алар 44-ФЗ номерлы Федераль законның 68 нче матдәсендәге 18 нче өлеше нигезендә төркемләп тәртипкә салынган һәм аларга карата мондый аукцион турында документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килү турында Карар кабул ителгән булырга тиеш, яки, әгәр мондый аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен карау нигезендә анда катнашкан барлык катнашучылар арасыннан билгеләнгән таләпләргә бердән артык ләкин биштән азрак гаризаның туры килү турында Карар кабул ителгән икән, шулай ук аларның идентификация номерлары турында мәгълүмат, мондый аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның аның турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында яки туры килмәве турында карар һәм мондый аукционда катнашучыга туры килми торган 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен, анда катнашуга гариза бирүче мондый аукцион турында документ нигезләмәләренә туры килми торган документ нигезләмәләрен

күрсәтеп, мондый аукционда катнашу өчен гариза нигезләмәләренә туры килмәү турында карар, Бердәм комиссиянең һәр әгъзасының мондый аукционда катнашу өчен һәр гаризага карата карары турында мәгълүмат булырга тиеш.

5.7.14. Контрактның иң түбән бәясен тәкъдим иткән һәм гаризасы әлеге аукцион турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килгән электрон аукцион катнашучысы җиңүче дип таныла.

5.7.15. Бердәм комиссия тарафыннан электрон аукцион турындагы документта билгеләнгән таләпләргә анда катнашу өчен бирелгән барлык гаризаларның икенче өлешләре күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү яки бер гаризаның икенче өлеше генә туры килү турында Карар кабул ителгән очракта, мондый аукцион үтмәгән дип таныла.

5.7.16. Әгәр анда катнашу өчен бирелгән гаризалар бирү срогы тәмамланганнан соң, бары бер гариза гына бирелгән булып электрон аукцион үтмәгән дип табылса, Бердәм комиссия әлеге гаризаны һәм тиешле документларны кабул итү датасыннан башлап өч эш көне дәвамында әлеге гаризаны һәм документларны 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә һәм билгеләнгән аукцион документларына туры килү-килмәү мәсьәләсен карый һәм электрон мәйданчык операторына Бердәм комиссия әгъзалары кул куйган электрон аукционда катнашу өчен бирелгән бердәнбер гаризаны карау беркетмәсен җибәрә. Аталган беркетмә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

- электрон аукционда катнашу өчен бердәнбер гариза биргән катнашучының гаризасы контракт системасы турындагы закон һәм мондый аукцион турындагы документ таләпләренә туры килүе турында яки мондый карарны нигезләп, әлеге таләпләргә туры килмәү турындагы, шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен һәм (яки) электрон аукцион турындагы документларны күрсәтеп чыгарылган карар;

- Бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның мондый аукционда катнашучының һәм ул биргән гаризаның 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм әлеге аукцион турындагы документ таләпләренә туры килүе турында яки әлеге катнашучының һәм аның гаризасының күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве турындагы карары.

5.7.17. Әгәр Бердәм комиссия тарафыннан, аукционда катнашу өчен гариза биргән бер генә катнашучыны әлеге сатып алуның катнашучысы дип тану турында карар кабул итү нәтиҗәсендә электрон аукцион үтмәгән дип табылса, Бердәм комиссия заказчы тарафыннан кабул иткән әлеге гаризаның икенче өлешен алган көннән соң өч эш көне дәвамында бердәнбер катнашучының гаризасын һәм тиешле документларын 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә һәм күрсәтелгән аукцион турындагы документларга туры килү-килмәвен карый һәм электрон мәйданчык операторына Бердәм комиссия әгъзалары имзалаган бердәнбер катнашучының гаризасын карау беркетмәсен җибәрә. Күрсәтелгән беркетмә үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- электрон аукционның бердәнбер катнашучысы һәм аңа тапшырылган

гаризаның 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм мондый аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килүе турында яки әлеге катнашучы һәм аның биргән гаризасының, әлеге карарны нигезләп, шул исәптән 44-ФЗ номерлы

Федераль закон нигезләмәләрен һәм (яки) бу аукцион турындагы бердәнбер гариза туры килми торган документларны күрсәтеп аның күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве турында карар;

- Бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның мондый аукционның бердәнбер катнашучысының анда катнашу өчен 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм әлеге аукцион турындагы документ таләпләренә туры килүе яки әлеге катнашучы һәм аның гаризасының шундый таләпләргә туры килмәве турындагы карары.

5.7.18. Әгәр үткәрелә башлаганнан соң 10 минут эчендә анда катнашучыларның берсе дә контракт бәясе турында тәкъдим бирмәвенә бәйле рәвештә электрон аукцион үтмәгән дип табылса, Бердәм комиссия заказчы тарафыннан мондый аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаларның икенче өлешен һәм тиешле документларны алган көннән алып өч эш көне дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә һәм әлеге аукцион турындагы документларга туры килү-килмәүвен карый һәм Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган мондый аукцион нәтиҗәләрен ясау беркетмәсен электрон мәйданчык операторына җибәрә. Күрсәтелгән беркетмә үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- электрон аукционда катнашучыларның һәм алар тарафыннан тапшырылган гаризаларның 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм мондый аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килүе турында яки әлеге катнашучыларның һәм аларның гаризаларының әлеге карарны нигезләп, 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм (яки) мондый аукцион турындагы документларга туры килмәве турында, шул исәптән әлеге гаризалар, аларның эчтәлеге әлеге аукцион турындагы документ таләпләренә туры килми торган мондый аукцион турындагы документ нигезләмәләрен күрсәтеп чыгарылган карар;

- Бердәм комиссиядәге һәр әгъзаның мондый аукционда катнашучыларның һәм алар тарафыннан тапшырылган гаризаларның 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм мондый аукцион турындагы документ таләпләренә туры килүе яки әлеге катнашучыларның һәм алар биргән гаризаларының әлеге таләпләргә туры килмәве турындагы карары.

5.7.19. Электрон аукцион үткәрү юлы белән тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү процедурасын тормышка ашырганда Бердәм комиссия шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә башка гамәлләр дә башкара.

## 5.8. Катировкалар соратып алу

5.8.1. Бердәм комиссия котировкалар соратып алуда катнашу өчен гаризалар салынган конвертларны котировкалар соравын үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән вакытта һәм урында ача.

5.8.2. Кергән барлык конвертларны ачу, шулай ук мондый гаризаларны карау һәм бәяләү бер көндә башкарыла. Мондый гаризалар салынган конвертларны ачу урыны, көне, вакыты, исеме (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик зат өчен), котировкалар соратып алуларда катнашучыларның барысының да почта адресы, котировкалар соратып

алуда катнашу өчен гариза салынган конверт, әлеге гаризаларда күрсәтелгән контракт бәясе турында тәкъдимнәр шундый гаризалар салынган конвертларны ачкан вакытта игълан ителә.

5.8.3. Котировкалар соратып алуда катнашучыларның гаризалары салынган конвертларны ачар алдыннан Бердәм комиссия әлеге конвертларны ачкан вакытта катнашучыларга котировкалар соратып алуда катнашу өчен гаризалар бирү мөмкинлеге турында игълан итәргә тиеш.

5.8.4. Бер катнашучының котировкалар соратып алуда катнашу өчен ике һәм аннан да күбрәк гариза бирү очрагы ачыкланган очракта, элек әлеге катнашучының бирелгән гаризаларын кире алынмаган очракта, котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән барлык гаризалары да каралмый һәм кире кайтарыла.

5.8.5. Котировкалар соратып алуның җиңүчесе дип котировкалар соратып алуда катнашу өчен гариза биргән, әлеге котировкалар соратып алу үткәрү турындагы хәбәрдә билгеләнгән барлык таләпләргә туры килгән, һәм анда товарның, эшнең яки хезмәтләрнең иң түбән бәясе күрсәткән катнашучы танылa. Товар, эш яки хезмәт күрсәтүләрнең иң түбән бәясе берничә катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән очракта, аның җиңүчесе дип котировкалар соратып алуда катнашу өчен гаризасы шундый ук бәя тәкъдим ителгән котировкалар соратып алуда катнашучыларының гаризаларыннан алдарак килгән катнашучы танылa.

5.8.6. Әгәр гаризалар котировкалар соратып алу үткәрү турындагы хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә яисә мондый гаризаларда тәкъдим ителгән товар бәясе, эш яки хезмәтләр котировкалар соратып алу үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч (максималь) бәядән артып китсә, яки котировкалар соратып алуда катнашучы 44-ФЗ номерлы Федераль законның 73 матдәсендәге 3 өлешнең 1, 2, 4-7 пунктларда каралган (44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очракыннан тыш) документлар һәм мәгълүмат тапшырмаган очракта, Бердәм комиссия котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризаларны карамый һәм кире кага. Башка сәбәпләр буенча котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны кире кагу рөхсәт ителми.

5.8.7. Котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризаларны карау һәм бәяләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, анда заказчы турында, контрактның төп шартлары турында, котировкалар соратып алуда катнашу өчен гариза биргән барлык катнашучылар турында, кире кагу сәбәбе күрсәтелгән (шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен һәм котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларда булган тәкъдимнәрне, котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларда булган тәкъдимнәрне, котировкалар соратып алудагы тәкъдимнәрне, федераль законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозу турында хәбәр итү таләпләренә туры килми торган катировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризаларны кире кагуга нигез булган нигезләмәләрне күрсәтеп) гаризалары кире кагылган катнашучылар турында мәгълүмат, товарның, эш яки

хезмәт күрсәтүләрнең иң түбән бәясе турында тәкъдим, котировкалар соратып алуның җиңүчесе турында мәгълүмат, котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризасында контракт бәясен котировкалар соратып алу җиңүчесе кебек күләмдә тәкъдим иткән катнашучы яки контракт бәясен килешү буенча тәкъдим иткән контракт бәясе җиңүче тәкъдим иткән бәядән соң иң яхшы шартларда булган котировкалар соратып алу катнашучысы турында мәгълүмат.

5.8.8. Котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау һәм бәяләү беркетмәсе утырышта катнашучы барлык Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

5.8.9. Әгәр бердәм комиссия тарафыннан котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән барлык гаризалар кире кагылган яки мондый гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча шуларның берсе генә котировкалар соратып алуны үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән барлык таләпләргә туры килми дип табылган булса, котировкалар соратып алу үтмәгән дип танылa.

5.8.10. Котировкалар соратып алу юлы белән тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү процедурасын тормышка ашырганда Бердәм комиссия шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә башка гамәлләр башкара.

## 5.9. Электрон формада катировкалар соратып алу

5.9.1. Электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң килүче бер эш көне дәвамында Бердәм комиссия мондый соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карый.

5.9.2. Электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча бердәм комиссия котировкалар соратып алуны үткәрү турындагы хәбәрнамәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган, гаризаны һәм әлеге гариза биргән катнашучыны электрон формада котировкалар соратып алу катнашучысы дип тану турында карар, яисә гаризаның һәм (яки) катнашучының котировкалар соравын үткәрү турында хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве һәм 44-ФЗ номерлы Федераль законның 82.4 нче матдәсендәге 3 нче өлешендә каралган очракларда гаризаны кире кагу турында карар кабул итә.

5.9.3. Электрон формада котировкалар соратып алуда катнашучының гаризасы бердәм комиссия тарафыннан түбәндәге очракта кире кагыла:

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 82.3 нче матдәсендәге 9 нчы өлешендә каралган документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшырмау яки, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 82.3 нчематдәсендәге 9 нчы өлешенең 2нче пунктының «а» пунктчасында каралган мәгълүматтан һәм электрон документлардан тыш, аларга карата 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14нче матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу очракларыннан тыш, дөрес булмаган мәгълүмат бирелгәндә;

- 44-ФЗ номерлы Федераль законның 82.3 матдәсендәге 9 өлештә каралган мәгълүматның мондый таләпне үткәрү турында хәбәр итү таләпләренә туры килмәгәндә.

5.9.4. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 82.4 матдәсендәге 3 өлештә каралмаган сәбәпләр буенча электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны кире кагу рөхсәт ителми.

5.9.5. Электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау беркетмәсендә теркәлә һәм анда Бердәм комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге гаризаларны карау вакыты тәмамланганнан соң кул куела. Күрсәтелгән беркетмә үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- әлеге гаризаларны карау урыны, көне һәм вакыты турында;
- электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларның идентификация номеры турында мәгълүмат;
- кире кагу сәбәпләрен нигезләп (шул исәптән 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен һәм электрон формада котировкалар соратып алу үткәрү турында хәбәрнамә нигезләмәләрен, бу катнашучыларның электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризалары әлеге котировкалар соратып алу турында хәбәрнамә таләпләренә туры килми торган тәкъдимнәрне, катировкалар соратып алуда катнашу өчен биргән гаризаларын кире кагуга нигез булып торган нигезләмәләрне күрсәтеп) котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны кире кагылган турында мәгълүмат;
- Бердәм комиссия әгъзаларының мондый сорауда катнашучыларның гаризаларына карата кабул ителгән карары турында.

5.9.6. Электрон формада котировкалар соратып алуның җиңүчесе дип электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен биргә гаризасы әлеге соратып алуны үткәрү турында хәбәрдә билгеләнгән барлык таләпләргә туры килгән, анда товарның, эшнең яки хезмәтләрнең иң түбән бәясе күрсәтелгән һәм беркетмәдә беренче тәртип номеры бирелгән электрон формада котировкалар сортып алу катнашучысы таныла. Электрон формада котировкалар соратып алуда иң түбән бәяләр, эш яки хезмәт күрсәтү тәкъдим иткән, электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризасы шундый ук бәя тәкъдим ителгән катнашучыларның гаризаларыннан алдарак килгән электрон формада котировкалар соратуында катнашучы җиңүче дип танyла.

5.9.7. Әгәр электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча бердәм комиссия электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән барлык гаризаларны кире какса яки бары тик бер генә шундый гариза гына электрон формада котировкалар соравын үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән барлык таләпләргә туры килә дип танылган булса, электрон формада котировкаларны соратып алу үтмәгән дип танyла. Электрон формада котировкалар соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау беркетмәсендә электрон

формада котировкалар соравын үтмәгән дип тану турында мәгълүмат булырга тиеш.

## 5.10. Тәкъдимнәр соратып алу

5.10.1. Бердәм комиссия тарафыннан тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен гаризалар салынган конвертлар ачыла. Соратып алуда катнашучылар тарафыннан тәкъдимнәр соравын үткәрү турындагы хәбәр һәм (яки) тәкъдимнәр соравын үткәрү турындагы документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми торган яки дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта, шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган очракларда әлеге гаризаларны биргән тәкъдимнәрне сорауда катнашучылар читләштерелә һәм аларның гаризалары бәяләнми. Әгәр тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы үзенең күрсәтелгән өстенлекләрен ия булуын белдерсә, яисә моны дәлилләүче документларның күчермәләрен, шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган документларны тапшырган очракта, күрсәтелгән норматив хокукый актларның гамәлдә булуына кагыла торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очрагында яисә мондый документларның күчермәләре, аларга карата 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очрагыннан тыш, сатып алу катнашучысының биргән гаризасында 44-ФЗ номерлы Федераль законның 28 һәм 29 матдәләре нигезендә мондый катнашучының өстенлекләр алу хокукын раслаучы документлар бирелмәгән булмауга бәйле рәвештә читләштерелергә тиеш түгел.

Тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы читләштерелгән очракта аның нигезләре тәкъдимнәр соравын үткәрү беркетмәсендә теркәлә.

Тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы тарафыннан ике һәм аннан да күбрәк гариза бирү очрагы ачыкланганда, андый катнашучының гаризасы каралмый һәм үзенә кире кайтарыла.

5.10.2. Тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен гаризалар салынган конвертларны ачу урыны, көне һәм вакыты турында мәгълүмат, тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен гариза бирүченең исеме (юридик зат өчен), һәр катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик зат өчен), тәкъдимнәр соратып алуда катнашучыларның почта адресы, тәкъдимнәр соратып алуны үткәрү турындагы документларда каралган мәгълүмат һәм документларның булуы, тәкъдимнәр соратып алуда күрсәтелгән контрактны үтәү шартлары, тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны бәяләү критерийлары, әлеге конвертлар ачылганда игълан ителә һәм тәкъдимнәр соратып алуны үткәрү беркетмәсенә кертелә.

5.10.3. Сорауда катнашучыларның барлык гаризалары да тәкъдимнәр соратып алу турындагы документларда күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәяләнә, таблицалар рәвешендә теркәлә һәм тәкъдимнәр соравын үткәрү беркетмәсенә теркәлә, шуннан соң иң яхшысы дип танылган гаризада булган

контрактны үтәү шартлары яисә бердәнбер гаризада булган шартлар игълан ителә.

5.10.4. Иң яхшы дип танылган гаризада булган контрактны үтәү шартларын яисә бердәнбер гаризада булган шартларны игълан иткәннән соң, тәкъдимнәрне соратып алу тәмамлана, тәкъдимнәрнең соратып алу өчен бердәм гариза биргән тәкъдимнәрнең барлык катнашучыларына яисә соратып алуда катнашучыга соңгы тәкъдимне соратып алу датасыннан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрергә тәкъдим ителә.

5.10.5. Әгәр барлык катнашучылар да тәкъдимнәр соратып алу вакытында анда катнашу өчен ахыргы тәкъдим җибәрүдән баш тартса, тәкъдимнәр соратып алу тәмамлана. Сорауда катнашучыларның соңгы тәкъдимнәрне җибәрүдән баш тартуы тәкъдимнәр соравын үткәрү беркетмәсендә теркәлә.

5.10.6. Соңгы тәкъдимнәр салынган конвертларны ачу бердәм комиссия тарафыннан тәкъдимнәр соравын үткәрү тәмамланганнан соң икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла һәм йомгаклау беркетмәсендә теркәлә. Соңгы тәкъдимнәрне җибәргән тәкъдимнәрне сорауда катнашучылар ахыргы тәкъдимнәр салынган конвертларны ачканда катнаширга хокуклы. Тәкъдимнәрне соратып алу катнашучысының контрактны үтәү шартларын үз эченә алган ахыргы тәкъдиме катнашучы биргән гаризада күрсәтелгән тәкъдимнәрне соратып алуда катнашу өчен билгеләнгән шартларны начарлата алмый. Катнашучы әлеге таләпнең тәкъдимнәрен үтәмәгән очракта, мондый катнашучының ахыргы тәкъдиме кире кагыла һәм мондый катнашучыга башта бирелгән тәкъдим ахыргы тәкъдим санала.

5.10.7. Ахыргы тәкъдимне откан ахыргы тәкъдим булып тәкъдимнәр соравын үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән критерийлар нигезендә, заказчы тарафыннан товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә куелган таләпләргә иң яхшысы туры килә торган ахыргы тәкъдим санала. Әгәр дә берничә соңгы тәкъдимдә контрактны үтәү шартлары бер үк төрле булса, ахыргы тәкъдимне отучы дип үз тәкъдимен башкалардан алдарак җибәргән катнашучы танила. Йомгаклау беркетмәсендә сорауда катнашучыларның соңгы тәкъдимнәрендә күрсәтелгән барлык шартлар да, ул ахыргы тәкъдимнәрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән, мондый ахыргы тәкъдимнәргә тәртип номерларын һәм җиңүченең соратып алу шартларын бирү турында кабул ителгән Карар да теркәлә. Йомгаклау беркетмәсе һәм тәкъдимнәр соравын үткәрү беркетмәсе йомгаклау беркетмәсенә кул куелган көнне Бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

5.10.8. Тәкъдимнәрне соратып алу юлы белән тәэмин итүчене (подрядчы, башкаручыны) билгеләү процедурасын тормышка ашырганда Бердәм комиссия шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре нигезендә башка гамәлләр дә башкара.

## 5.11. Электрон формада тәкъдимнәрне соратып алу

5.11.1. Электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучылар электрон формада тәкъдимнәр соравын үткәрү турында хәбәр белән билгеләнгән

таләпләргә туры килми торган һәм (яки) электрон формада тәкъдимнәр соратып алу турында документлар белән билгеләнгән таләпләргә туры килми торган электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучылар, яки дөрес булмаган мәгълүмат биргән катнашучылар, шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсе нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган очракларда Бердәм комиссия тарафыннан читләштерелә һәм аларның заявкалары бәяләнми. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 83.1 нче матдәсендәге 9 нчы өлешенең 4 нче пунктында, шулай ук 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93.1 нче матдәсендәге 9 нчы өлешенең 5 нчы пунктында каралган электрон документлары, шулай ук гаризасында 44-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче матдәсендә каралган тыю билгеләнгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу очракыннан тыш, 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93.1 нче матдәсендәге 9 нчы өлешенең 5 нче пункты белән билгеләнгән катнашу өчен бирелгән дкуметлар булмау сәбәпле, катнашучы читләштерелергә тиеш түгел. Электрон формада тәкъдимнәр Соратып алуда катнашучыны читләштерү нигезләре электрон формада тәкъдимнәр соратып алу беркетмәсендә теркәлә.

5.11.2. Электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучыларның барлык бирелгән гаризалары электрон формада тәкъдимнәр соратып алу үткәрү турындагы документта күрсәтелгән критерийлар нигезендә Бердәм комиссия тарафыннан бәяләнә, таблицалар рәвешендә теркәлә һәм электрон формада тәкъдимнәр соратып алу беркетмәсенә теркәлә. Күрсәтелгән беркетмәгә иң яхшысы дип танылган гариза турында мәгълүмат яки электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен бердәнбер гаризада булган шартлар кертелә.

5.11.3. Электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризаларны карау һәм бәяләү срогы тәмамланганнан соң да соңга калмыйча заказ бирүче бердәм мәгълүмат системасына соратып алуда катнашудан читләштерелгән тәкъдимнәр исемлеген үз эченә алган, гаризада булган иң яхшысы дип танылган контрактны үтәү шартларын яки бердәнбер гаризада катнашу өчен булган шартларны күрсәтеп, әлеге гариза җибәрелгән электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучыны күрсәтмичә, соратып алу беркетмәсеннән өземтә урнаштыра.

5.11.4. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 83.1 нче матдәсендәге 20нче өлеше нигезендә тәкъдимнәрне электрон формада соратып алу беркетмәсеннән өземтә урнаштырганнан соң, бер эш көне эчендә барлык катнашучылар яки бу сорауда катнашу өчен бердәм гариза биргән электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы, ахыргы тәкъдим җибәрергә хокуклы. Шул ук вакытта контрактны үтәү шартларын үз эченә алган мондый сорауда катнашучының ахыргы тәкъдиме гаризада күрсәтелгән әлеге сорауда катнашу өчен бирелгән шартларны начарайта алмый. Электрон формасындагы тәкъдимнәрне соратып алу таләпләре үтәлмәгән очракта, әлеге катнашучының ахыргы тәкъдиме кире кагыла һәм күрсәтелгән катнашучы тарафыннан алдарак бирелгән тәкъдим соңгысы дип санала.

5.11.5. Әгәр электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашучы 44-ФЗ номерлы Федераль законның 83.1 нче матдәсендәге 21 нче өлеше белән

билгеләнгән вакытка ахыргы тәкъдимен җибәрмәсә, ахыргы тәкъдимнәр дип электрон формада тәкъдимнәр соратып алуда катнашу өчен бирелгән гаризалар танылa.

5.11.6. Катнашучылардан килгән ахыргы тәкъдимнәрне карау әлеге тәкъдимнәрне тапшыру срогы тәмамланганнан соң икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре йомгаклау беркетмәсендә теркәлә.

5.11.7. Ахыргы тәкъдимне откан дип әлеге электрон формадагы тәкъдимнәр соравын үткәрү турындагы документларда күрсәтелгән критерийлар нигезендә заказчының товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә куелган таләпләргә иң яхшы туры килә торган ахыргы тәкъдим санала. Әгәр берничә соңгы тәкъдимдә контрактны үтәү шартлары бер үк төрле булса, гаризасын башка кашнашучылардан адарак биргән электрон формадагы тәкъдимнәр сратып алу катнашучысы танылa. Йомгаклау беркетмәсендә әлеге ахыргы тәкъдимнәрне бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән, мондый ахыргы тәкъдимнәргә тәртип номерларын бирү турында карар һәм электрон формада тәкъдимнәр соратып алу җиңүчесе шартлары белән берлектәэлектрон формадагы тәкъдимнәр соратып алуда катнашучыларның соңгы тәкъдимнәрендә күрсәтелгән барлык шартлары да теркәлә. Йомгаклау беркетмәсе һәм электрон формадагы тәкъдимнәр соратып алуны үткәрү беркетмәсе вәкаләтле орган тарафыннан Бердәм мәгълүмат системасында һәм йомгаклау беркетмәсенә кул куелган көндә электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

## 6. Бердәм комиссия төзү һәм аның эшләү тәртибе

6.1. Комиссия заказ бирүчеләрнең даими эшләүче коллегиаль органы булып тора.

6.2. Комиссиянең персональ составы, шул исәптән Бердәм комиссия рәисе Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия составына кимендә биш кеше – комиссия әгъзасы керергә тиеш. Рәис комиссия әгъзасы булып тора.

6.3. Әдәбият яки сәнгать әсәрләрен төзү, башкару (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе буларак), прокатны финанслау яки милли фильмнар күрсәтү өчен конкурслар уздырганда бердәм комиссия составына тиешле әдәбият яки сәнгать өлкәсендә иҗат һөнәрләре вәкилләре кертелергә тиеш. Мондый затлар саны Бердәм комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 процент тәшкил итәргә тиеш.

6.4. Бердәм комиссия составында күбесенчә сатып алулар өлкәсендә һөнәри, яңадан әзерлек яки квалификация үстерү курслары узган затлар, шулай ук сатып алу объекты буенча махсус белемнәре булган затлар булырга тиеш.

6.5. Бердәм комиссия әгъзалары буларак, конкурс документларына эксперт сыйфатында җәлеп ителгән физик затлар, квалификация алды сайлап алуны үткәрүчеләр, конкурста катнашучыларның өстәмә таләпләргә туры килүен бәяләү барышында торган конкурста катнашу өчен бирелгән гаризаларны кабул итүчеләр катнаша алмый. Шулай ук әлеге комиссия әгъзалары булып тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү нәтиҗәләре

белән кызыксынучы физик затлар, шул исәптән мондый билгеләүдә катнашу өчен гаризалар биргән яки әлеге гаризаларны биргән оешмалар штатында торучы физик затлар да була алмый. Моннан тыш, аталган комиссия әгъзалары сыйфатында сатып алу катнашучылары йогынты ясарга сәләтле физик затлар була алмый. Аерым алганда, мондый физик затлар булып әлеге оешмаларда катнашучылар (акционерлар), аларның идарә органнары әгъзалары, сатып алуларда катнашучы җитәкчесе белән гаилә корып торучы яки якын туган (турыдан-туры туганнар һәм башка туганнар (ата-аналар һәм балалар, бабайлар, әбиләр һәм оныклары), тулы булмаган (уртак әтисе яки әнисе булган) туганнар, сатып алу катнашучысы җитәкчесен уллыкка алучылар яки аның үзенең уллыкка алынган баласы булган физик затлар. Бердәм комиссия әгъзалары сыйфатында сатып алулар өлкәсендә турыдан-туры контрольне гамәлгә ашыручы контроль органының вазыйфаи затлары була алмый. Бердәм комиссия составында күрсәтелгән затлар булуы ачыкланган очракта, заказчылар аларны күрсәтелгән таләпләргә җавап бирә торган башка физик затлар белән алыштырылырга тиеш.

6.6. Комиссия әгъзаларын алыштыру заказчылар карары буенча гына рөхсәт ителә.

6.7. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 50 проценты катнашса, үз функцияләрен гамәлгә ашырырга хокуклы. Комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында үз вакытында хәбәр ителергә тиеш. Комиссия әгъзалары тарафыннан читтән торып тавыш бирү юлы белән карар кабул итү, шулай ук аларның вәкаләтләрен башка затларга тапшыру рөхсәт ителми.

6.8. Бердәм комиссия әгъзаларына комиссия утырышларының урыны, көне һәм вакыты турында хәбәр итү, мондый утырышны уздыру көненә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча, утырышның көн тәртибе турында мәгълүмат булган чакыру җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Чакыру әзерләү, аны рәискә кул кую һәм комиссия әгъзаларына җибәрү Бердәм комиссия секретаре тарафыннан башкарыла.

6.9. Бердәм комиссия әгъзалары хокуклы:

6.9.1. Конкурста катнашу өчен гариза бирүченең документлары һәм белешмәләре, аукцион, котировкалар соратып алу, тәкъдимнәр соратып алулар белән танышырга;

6.9.2. Бердәм комиссия утырышларында көн тәртибе мәсьәләләре буенча чыгыш ясарга;

6.9.3. Бердәм комиссия төзегән беркетмәләрнең дөреслеген, шул исәптән бу беркетмәләрдә үз чыгышларының дөреслеген тикшерергә.

6.10. Бердәм комиссия әгъзалары бурычлы:

6.10.1. Игътибарга лаеклы сәбәпләр аркасында (вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек, командировка һәм башка игътибарга лаеклы сәбәпләр) килеп чыккан очраклардан тыш, Бердәм комиссия утырышларында катнашу;

6.10.2. Үз компетенциясе кысаларында карарлар кабул итү.

6.11. 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм әлеге Нигезләмә таләпләрен бозып кабул ителгән Бердәм комиссия карары өчен сатып алуларның теләсә кайсы катнашучысына карата 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән

тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин һәм сатып алулар өлкәсендә контроль орган карары буенча гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

6.12. Бердәм комиссия рәисе яисә аны алмаштыручы зат:

- бердәм комиссия эше белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, әлеге Нигезләмәнең үтәлешен тәэмин итә, комиссия әгъзасы хокукларын тормышка ашыра һәм вазыйфаларын башкара;

- Бердәм комиссия утырышын ача һәм алып бара;

- кирәк булган очракта, Бердәм комиссия алдында экспертларны эшкә тарту мәсьәләсен чыгара.

6.13. Бердәм комиссия сәркатибе, яки аны алмаштыручы зат:

- бердәм комиссия утырышларын әзерләүне, кирәкле документларны рәсмиләштерүне һәм җибәрүне, аларның функцияләренә кагылышлы барлык мәсьәләләр (шул исәптән комиссия эшендә катнашучы затларга утырышлар үткәрү вакыты һәм урыны турында белдерү ясау һәм комиссия әгъзаларын кирәкле материаллар белән тәэмин итү) буенча бердәм комиссия әгъзаларына мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

- Бердәм комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

6.14. Бердәм комиссия әгъзалары 44-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук Россия Федерациясенең һәм әлеге Нигезләмәнең, башка норматив хокукый актларын бозуда гаепле булган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, җинаять җаваплылыгы алып баралар.

**Эшләр белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**